Нурлыкклар

Буа районы “Кояшкай” балалар бакчасы гәҗите

№6 Февраль, 2021 ел



## 21 февраль – Халыкара телләр көне

ЮНЕСКО тарафыннан игълан ителгән әлеге халыкара бәйрәм дөньядагы телләрне саклау, аларны киләчәк буынга исән-имин җиткерү максатыннан оешты. Бүгенге көндә галимнәр Җир шарында 7 меңнән артык тел булуын әйтәләр. Һәр халыкның теле үзенчәлекле, күп телләр белү дөньяга карашны киңәйтә, төрле милләт халкының мәдәниятен тирәнрәк белергә ярдәм итә.Ләкин туган тел ул бер генә. Безнең телебез – татар теле. Шуңа күрә һәр татар кешесе үз теленә хөрмәт белән карарга тиеш. Сабыйларыбызның теле туган телдә ачылсын. Телебезнең кулланылыш даирәсен киңәйтү, аны балаларыбызга тапшыру – безнең төп бурычыбыз.

Хөрмәтле милләттәшләр, кадерле дуслар! Барыгызны да халыкара туган тел көне белән котлыйм. Татар халык мәкале: “Туган телне кадерләгән халык кадерле булыр”, – ди. Туган телләребезне саклыйк, яклыйк, чөнки милләтнең яшәешендә туган тел иң мөһим урыннарның берсен алып тора.

***Балалар бакчасы мөдире Э.З.Абузәрова***

### Бүгенге санда


1. 21 нче февраль – Телләр көне
2. Проект өстендә эш
3. Күңелле сәхифә


## БАКЧАДА ТУГАН ТЕЛ КӨНЕ!





Безнең туган телебез – нинди генә булмасын татар, рус, чуаш телеме, ул һәр милләт өчен бик газиз һәм кадерле.

Бакчасында туган телләр көненә багышланган “Туган телем- иркә гөлем”диеп исемләнгән бәйрәм үтте. Балалар бәйрәмдә туган телебезгә булган мәхәббәтебезне җыр, бию, шигырь, уеннар аша күрсәттеләр.

И туган тел, и матур тел,<br>
әткәм-әнкәмнеңтеле!<br>
Дөньяда күп нәрсә белдем<br>
син туган тел аркылы.

Габдулла Тукай





# "Балалар анимациясе-мөмкинлекләр киңлеге"



Бүгенге көндә мәктәпкәчә балалар бакчаларында татар телендә балаларга күрсәтү өчен мультфильмнар бик аз. Ә үз куллары белән ясалган тематик мультфильмнар булдыру аз формалаштырылган, йә бөтенләй кайбер сәбәпләр аркасында тәкъдим ителмәгән. Моңа балалар бакчаларының техник җиһазланышы, компьютер технологияләре өлкәсендә педагогларның компетентлыгы җитәрлек дәрәҗәдә булмавы тәэсир итә.

Менә шуңа да:" Нигә үз кулларыбыз белән балалар, педагоглар һәм ата-аналар уйлап тапкан сюжетлар кулланып мультипликацион фильм ясап карамаска," – дигән сорау куелды.

Бу идея безгә актуаль булып тоелды, без татар телендәге анимацион фильмнар төшерү белән шөгыльләнергә булдык.

Безнең балалар бакчасында «Нурчыклар» мультстудиясе оешты. Педагоглар мәктәпкәчә яшьтәге балалар һәм ата-аналар белән берлектә Татарстан Республикасының ике дәүләт телендәге мультфильмнар коллекциясе булдыру эшенә тотынды. Мультфильмнар кабатланмый торган иҗади манера да булдырыла. Мультикларның тавышын балалар үзләре яздыралар. Проект танып-белү,сөйләм, сәнгать-эстетик үсешенә юнәлтелгән һәм милли мәдәният чыганакларына, туган якны өйрәнүгә җәлеп итү, инновацион методикалар һәм технологияләр кулланып, балаларны татар телен өйрәтү үсешен баетуны күздә тота.

Кыска гына вакыт эчендә ясалган мультфильмнар бакчада зур популярлык казанды. "Читек маҗарасы" мультфильмы конкурсларда җиңү яулады.

Сезнең игътибарга кайбер мультфильмнарны тәкъдим итәбез. Аларны QR код ярдәмендә кереп карарга мөмкин. Шулай ук балаларның эш вакытында төшкән фотоларын да карарга мөмкин.

***Өлкән тәрбияче Санатуллова Р.М***




















# Күңелле эш мизгелләре



# Мульткроссвордны чиш!

Кроссвордны дөрес чишсәгез вертикаль буенча Габдулла Тукайның мультгероен табарсыз.












































«Нурчыклар» гәҗитен гамәлгә куючы:
Татарстан Республикасы Буа шәһәренең катнаш төрдәге “Кояшкай” балалар бакчасы” муниципаль бюджет учреждениесе

Редколлегия әгъзалары:
Гыйниятуллина Д.Р.

Безнең адрес:
422430,Буа шәһәре,
Арефьева урамы, 13 йорт

Тел. (843)743-13-09
E-mail: colnush-bua@mail.ru